**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы «Зур Полянка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Александровка авыл торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

**2025 елның 24 ноябреннән** **№ 2**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Зур Полянка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Александровка авыл торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2026 елда Алексеевск муниципаль районының « Зур Полянка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Александровка авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлек студентларыннан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан,МХО да катнашучы һәм МХО инвалидларыннан тыш,1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү,каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу,санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү;

- су белән тәэмин итү һәм юынтык суларны агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пункт территориясен төзекләндерү.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Зур Полянка авыл җирлеге Башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

2. Әлеге карарны Зур Полянка авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә , Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Алексеевск муниципаль районының**
**Зур Полянка авыл җирлеге башлыгы**
**урынбасары, 4 нче сайлау округы**
**депутаты** **З.А. Кузнецова**